РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

16 март 2026 ел № 3-8

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 24 апрелендәге 9-31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан социаль гарантияләр тәэмин итү, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 26 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 24 апрелендәге 9-31 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 нчы кушымтаның 1 пунктындагы «биш тапкыр» сүзен «ун тапкыр» сүзенә алмаштырырга, «һәм һәр алдагы тулы ел өчен өстәмә 0,5 ден акчалата

түләү, әмма акчалата түләүнең уннан артык күләменнән артмаска тиеш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 9.1 кушымтасында:

1 пунктта «биш тапкыр» сүзен «ун тапкыр» сүзенә алмаштырырга, «һәм һәр алдагы тулы ел өчен өстәмә рәвештә 0,5әр акчалата түләү, әмма даими нигездә эшләүче сайланулы вазыйфаи затның акчалата түләүенең уннан да артыграк булмаган күләме» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта өченче абзацны төшереп калдырырга; дүртенче абзацта «айлык акчалата түләүнең 50 процентыннан артмаган күләмендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Буа муниципаль районы территориясендәге җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә йөкләргә:

алар чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә;

муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмәгән һәм әлеге органнарны техник тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү мәсьәләләрен муниципаль район башлыгы белән килештереп, үз хокукый актлары белән бертөрле җайга салырга.

4. Әлеге карар имзаланган вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш (http://pravo.tatrstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов